КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 июль г.Казань № 637

2020 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында» 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы һәм «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 елның 13 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2020 елның II кварталы өчен Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 9 668 сум, эшкә яраклы халыкка – 10 294 сум, пенсионерларга – 7 889 сум, балаларга – 9 713 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин